ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№__502_ от «__21__»____09___2018 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
2016 елның 27 нче январендә кабул ителгән
76 нчы санлы карарына үзгәрешләр
кертү хакында

"Россия Федерациясендә халыкның эш белән тәэмин ителеше турында" Россия Федерациясе Законының 24 нче статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Җәмәгать эшләрен оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында" 1997 ел, 14 июль, 875 нче санлы карары, Татарстан республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Россия Федерациясендә түләнелүче җәмәгать эшләрен башкаруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2016 ел, 21 апрель, 219 нчы санлы боерыгы нигезендә, "2014-2020 елларга Татарстан республикасы халкы мәшгульлегенә ярдәм итү" Дәүләт программасы чараларын тормышка ашыру максатында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1.Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 27.01.2017 ел, 76 нчы санлы карары белән расланган "Эшсез гражданнарны вакытлыча түләүле җәмәгать эшләренәураштыру нигезләмәсенә" түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 14 пунктның 7 абзацын, 14 пунктның 3 абзацын, 14 пунктның 2 абзацын, 17 пунктның 2 абзацын гамәлдән чыгарырга;

1.2. 13 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Гражданнарның түләнелүче җәмәгать эшләрендә катнашкан дәвер хезмәт стажын өзми һәм иминият пенсиясен билгеләгәндә исәпкә алына торган иминият стажына керә".

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының матбугат һәм массакүләм чаралары белән хезмәттәшлек секторына әлеге карарны интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы М.Р. Хуҗаҗанов